ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 өлешенең 17 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (II өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“17) оешмалар балансында исәптә торучы яңа булдырылган яисә 2014 елның 1 гыйнварыннан соң сатып алынган, социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турындагы килешү нигезендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру максатларында кулланыла торган мөлкәткә карата – Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территория резидентлары булган оешмалар. Ташлама күрсәтелгән мөлкәт исәпкә алынган айдан соң килә торган айның 1 числосыннан башлап, ләкин 2017 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган вакытта, социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турында килешү гамәлдә булган чорга, ләкин иң күбе 10 елга бирелә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон 2017 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да ким булмаган һәм оешмалар мөлкәтенә салым буенча чираттагы салым чорының 1 числосыннан иртәрәк булмаган вакытта гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 28 ноябре
№ 91-ТРЗ